ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 631 2016 елның 7 апреле

# 2016 елның янгын куркынычы янаган язгы-җәйге чорда икътисад, авыл хуҗалыгы җитештерүе, социаль-мәдәни-көнкүреш объектлары һәм «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлекләре торак пунктларының торак секторы объектларында янгынга каршы чаралар үткәрү турында

2016 елның язгы-җәйге чорында янгыннарны кисәтү һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе объектларының, социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларның һәм Түбән Кама районы торак пунктларының янгынга каршы торышын яхшырту максатларында карар бирәм:

1. 2016 елның язгы-җәйге янгын куркынычы чорына янгынга каршы чаралар планын расларга (кушымта).

2. 2016 елның 29 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Г. Нигъмәтҗановка, авыл җирлекләре башлыклары һәм хуҗалык җитәкчеләре белән берлектә, уртак утырышларда авыл хуҗалыгы җитештерүе объектларының, социаль-мәдәни-көнкүреш объектларының һәм торак секторның янгынга каршы чаралар планын үтәү буенча барлык чараларны кабул итеп, авыл хуҗалыгы җитештерүе объектларының, социаль-мәдәни-көнкүреш объектларының һәм торак секторның янгынга каршы торышын яхшырту мәсьәләләрен карарга.

3. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенә (Шиһапов К.Ф.) «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең авыл хуҗалыгы җитештерүе объектларын, бакча җәмгыятьләрен, балалар сәламәтләндерү лагерьларын һәм торак пунктларын тикшергәндә «Янгын куркынычсызлыгы турында» Россия Федерациясе Законы белән күзәтчелек эшчәнлеге органнарына бирелгән хокуклардан тулысынча файдаланырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В.Г. Серебряковка йөкләргә.

Җитәкче В.В. Федотов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2016 елның 7 апрелендәге
631 номерлы карары белән расланган
кушымта

2016 елның язгы-җәйге янгын куркынычы чорына
янгынга каршы чаралар планы

| № | Чаралар исеме | Үтәү вакыты | Үтәү өчен җаваплы | Үтәү турында билге |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Кызыксынган ведомстволар җитәкчеләре катнашында муниципаль берәмлекләр Башлыкларында киңәйтелгән киңәшмәләр үткәрүне оештырырга, аларда түбәндәге мәсьәләләрне карарга кирәк:<br>- Янгынга каршы чаралар үтәлешен оештыру һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы затларны билгеләү турында: булган минераллаштырылган полосаларны яңарту һәм яңаларын булдыру, бигрәк тә урман массивларында яки аларга якын урнашкан торак пунктлар янында, янгынга каршы урман ызаны булдыру, диләнке чүп-чарыннан арындыру, квартал урман ызаннарын һәм урман юлларын чистарту, урман массивларында һәм торак пунктларда урнашкан табигый су чыганакларын, янгын сүндерү техникасы белән су алу мәйданчыкларын төзекләндерү;<br>- Урман фонды җирләрендә янгынга каршы чаралар үтәлеше турында;<br>- Урман массивлары янындагы торак пунктларда ирекле янгын командалары һәм ирекле янгын дружинасы булдыру турында; | 2016 елның апреле | Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр идарәсенең<br>«Түбән Кама урман хуҗалыгы» ДБУ<br>«Татарстан Республикасы Янгын сагы» Баш идарәсенең Түбән Кама отряды<br>Күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге<br>ТР Түбән Кама районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе<br>ТР Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | - Торак пунктларда беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү буенча | | | |
| 2. | Торак пунктларда һәм икътисад тармаклары объектларында янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларын төзекләндерүгә, су чыганакларына керү юлларын төзекләндерүгә ирешү | 2016 елның май-июне | ТР Түбән Кама районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе<br>ТР Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары<br>Торак-коммуналь оешмалар<br>«Татавтодор» ААҖ Түбән Кама филиалы<br>Юл идарәсе | |
| 3. | Муниципаль җирлекләр җитәкчеләре белән берлектә урман янгыннары вакытында объектларга һәм торак пунктларга (саклагыч янгын полосалары урнаштыру, коры үсемлекне бетерү һ. б.) янгын күчү мөмкинлеген булдырмый торган чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру | 2016 елның апрель-мае | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары<br>Бакчачылык ширкәтләре рәисләре<br>«Түбән Кама урман хуҗалыгы» ДБУ | |
| 4. | Торак пунктлар территорияләрендә һәм бакчачылык массивларында санкцияләнмәгән чүплекләрне булдыруга юл куймау буенча чаралар комплексын кабул итәргә: чүп чыгаруга шартнамәләр төзү; чүп җыю өчен контейнерлар урнаштыру | бөтен янгын куркынычы чорында | ТР Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары<br>Бакчачылык ширкәтләре рәисләре<br>Торак-коммуналь оешмалар | |
| 5. | 2016 елга язгы-җәйге янгын куркынычы чорына әзерлек өлешендә икътисад тармаклары объектларын, балалар сәламәтләндерү лагерьларын һәм торак пунктларны тикшерүләр планы нигезендә планлы (планнан тыш) тик- | 2016 елның апрель-июне | КЭБ (күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге) инспекторлары | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | шерүләр үткәрергә | | | |
| 6. | Урып-җыю урыннарында, яңа уңыш һәм азык эшкәртү һәм саклау объектларында янгынга каршы чаралар комплексын тормышка ашырырга | 2016 елның 25 августына кадәр | КЭБ инспекторлары<br>Авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре | |
| 7. | Эчке эшләр органнары белән берлектә бакчачылык ширкәтләрендә янгынга каршы чараларны комплекслы эшләүне оештырырга | 2016 елның апрель-мае | КЭБ инспекторлары<br>Эчке эшләр идарәсе<br>Бакчачылык ширкәтләре рәисләре | |
| 8. | Янгыннарны кисәтү һәм кешеләрнең үлемен кисәтү проблемаларын массакүләм мәгълүмат чараларында даими яктыртырга | язгы-җәйге чорда | КЭБ<br>«Эфир» ҖЧҖ, «Түбән Кама телерадиокомпаниясе», «Нижнекамская правда» «Туган як», «Ваша газета» | |
| 9. | Язгы-кышкы янгын куркынычы чорында янгында кешеләрнең һәлак булуын кисәтү буенча экспресс-мәгълүмат һәм янгын куркынычсызлыгы чаралары турында белешмәлекләр әзерләргә | 2016 елның май-июне | КЭБ<br>«Бөтенроссия ирекле янгын җәмгыяте» Татарстан Республикасы бүлекчәсе | |
| 10. | Терлекләрне җәйге асрауга күчерү сәбәпле, терлекчелек биналарын электр калориферларыннан, су җылытучы казаннардан өзү буенча эш алып барырга | 2016 елның 7 маена кадәр | Авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре (килешү буенча) | |
| 11. | Янгыннар белән бәйле вәзгыятьне анализлауны исәпкә алып, предприятиеләр, оешмалар, шулай ук янгыннар белән имин булмаган хәл булган микрорайоннарны һәм торак пунктларны оператив тикшерү оештырырга | язгы-җәйге чорда | КЭБ | |
| 12. | Янгын-техник минимум программалары буенча җылылык белән тәэмин итүче җайланмаларга һәм агрегатларга хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затларны укытуны оештырырга | язгы-җәйге чорда | Авыл җирлекләре башлыклары<br>КЭБ инспекторлары<br>«Бөтенроссия ирекле янгын җәмгыяте» Татарстан Республикасы бүлекчәсе (килешү буенча) | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 13. | Барлык резерв янгын сүндерү һәм булган башка техниканы, шул исәптән мотопомпаларны тикшерергә һәм әзерлеккә китерергә | 2016 елның 7 маена кадәр | Авыл җирлекләре башлыклары<br>Авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре<br>«Татарстан Республикасы Янгын сагы» Түбән Кама янгын сүндерү һәм коткару гарнизоны (килешү буенча) | |
| 14. | «Түбән Кама урманчылыгы» ДБУ һәм «Түбән Кама урман хуҗалыгы» ДБУ белән берлектә, Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр идарәсенә 2016 елның җәйге чорында урман һәм торф янгыннары белән көрәш буенча үзара хезмәттәшлек мәсьәләләрен эшләргә: урман массивлары янындагы объектлар тирәсендә минераллаштырылган полосаларны сөрү һәм оештыру | 2016 елның 7 маена кадәр | «Түбән Кама урманчылыгы» ДБУ<br>«Түбән Кама урман хуҗалыгы» ДБУ<br>Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр идарәсе<br>Авыл җирлекләре башлыклары<br>Бакчачылык ширкәтләре рәисләре<br>Түбән Кама янгын сүндерү һәм коткару гарнизоны<br>Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр бүлегенең КЭД | |
| 15. | Коры, эссе һәм җилле һава торышы вакытында, шулай ук махсус янгынга каршы режим кертелгәндә, түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруны оештырырга:<br>а) учаклар ягуны, аерым участокларда янгын куркынычы булган эшләр башкаруны, мичләрне, кухня учакларын һәм | язгы-җәйге чорда | Авыл җирлекләре башлыклары<br>Бакчачылык ширкәтләре рәисләре<br>Авыл хуҗалыгы пред- | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | котельныйлар ягуны тыю;<br>б) Россия Федерациясенең ирекле янгын сүндерүчеләр һәм (яки) гражданнары белән патрульлек итүне оештыру;<br>в) янгыннарны сүндерүдә булган су ташу һәм җир техникасын куллану өчен әзерлек;<br>г) янгын куркынычсызлыгы чаралары һәм янгын вакытында булган гамәлләр турында гражданнар белән тиешле аңлату эшләре үткәрү | | приятиеләре җитәкчеләре<br>Түбән Кама янгын сүндерү һәм коткару гарнизоны<br>«Татарстан Республикасы Янгын сагы» ДУ Түбән Кама отряды<br>КЭБ<br>«Бөтенроссия ирекле янгын җәмгыяте» Татарстан Республикасы бүлекчәсе (килешү буенча) | |
| 16. | Гомуми кулланылыштагы территорияләрне, торак пунктларны, шул исәптән авыл җирлекләре, бакчачылык ширкәтләре территорияләрендә шәхси торак йортларны беренчел янгын сүндерү чаралары, янгынга каршы инвентарь, янгын вакытында кешеләргә тавыш белән хәбәр итү чарасы белән тәэмин итәргә | 2016 елның<br>7 маена кадәр | Авыл җирлекләре башлыклары<br>Бакчачылык ширкәтләре рәисләре | |
| 17. | Янгынны локальләштерү һәм кешеләрне һәм мөлкәтне коткару буенча Дәүләт янгынга каршы хезмәте бүлекчәләре килгәнче чаралар күрергә | язгы-җәйге чорда | авыл җирлекләре башлыклары | |
| 18. | Һәр җирлектә янгын куркынычсызлыгы чаралары турында халыкка мәгълүмат бирү буенча күрсәтмә агитация белән янгынга каршы стенд урнаштыру | 2016 елның<br>7 маена кадәр | авыл җирлекләре башлыклары | |
| 19. | «Торак-2016» операциясе кысаларында планлаштырылган эшне активлаштырырга | 2016 елның<br>марты-мае | авыл җирлекләре башлыклары<br>КЭБ<br>Түбән Кама янгын сүндерү һәм коткару гарнизоны<br>«Татарстан Республика- | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | сы Янгын сагы» ДУ Түбән Кама отряды<br>Эчке эшләр идарәсе<br>Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министр-лыгының Түбән Кама му-ниципаль районы социаль яклау идарәсе<br>«НАСКО» ААЖ | |
| 20. | Янгын куркынычы янаган зоналарда урнашкан, кешеләр күп була торган оешмаларның, учреждениеләрнең һәм торак пунктларның янгынга каршы торышына контрольне көчәйтергә | 2016 елның апрель-август ае | Түбән Кама янгын сүн-дерү һәм коткару гарни-зоны<br>«Татарстан Республикасы Янгын сагы» ДУ Түбән Кама отряды | |
| 21. | Торак пунктларны һәм торак фондын янгынга каршы саклауны арттыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыеннарын һәм халык белән очрашулар үткәрүне оештырырга | 2016 елның май-июне | Нигъмәтҗанов А.Г.<br>авыл җирлекләре башлыклары | |
| 22. | Ялгыз яшәүче өлкән гражданнар, инвалидлар һәм күпбалалы гаиләләрдә җылылык мичләрен һәм йорт эчендәге электр чыбыкларын бушлай ремонтлау, шулай ук аларның йортларын янгын сигнализациясенең автоном төтен датчиклары белән җиһазландыру мәсьәләсен карарга | 2016 елның 20 маена кадәр | авыл җирлекләре башлыклары<br>«Бөтенроссия ирекле янгын җәмгыяте» Татарстан Республикасы бүлекчәсе<br>Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министр-лыгының Түбән Кама му-ниципаль районы социаль яклау идарәсе | |
| 23. | 2008 елның 18 июлендәге 5663-16-2-10 номерлы Янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларын исәпкә алу һәм контрольдә тоту буенча инструкция нигезендә янгынга | 2015 елның апрель-мае | Түбән Кама янгын сүн-дерү һәм коткару гарни-зоны | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | каршы су чыганакларының 2 нче номерлы тикшерүне оештырырга, аның нәтиҗәләре турында авыл җирлекләре башлыкларына, объект җитәкчеләренә хәбәр итәргә. 1 нче һәм 2 нче номерлы тикшерү нәтиҗәләре буенча «ВК һәм ЭХ» АҖ, объектлар администрациясенә янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының төзек булмавы турында мәгълүмат җибәрергә. Янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының торышына бәйле проблемалы мәсьәләләрне гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләре тикшерүенә чыгарырга | | «Татарстан Республикасы Янгын сагы» ДУ Түбән Кама отряды<br>КЭБ | |
| 24. | Янгын мотопомпалары, ягулык-майлау материаллары, саклагыч киемнәр (янгын сүндерүченең сугышчан киеме), янгын сүндерү-техник кораллары (янгын җиңсәләре, тармаклар, күчмә эшләпәләр, көпшәләр һ. б.) сулыш органнарын индивидуаль яклау чарасы резервын булдыруны күздә тотарга, әлеге резервны тәүлекнең теләсә кайсы вакытында резервны янгын чыгу урынына алып килү тәртибен эшләргә. | 2016 елның апрель-мае | Авыл җирлекләре башлыклары<br>Түбән Кама янгын сүндерү һәм коткару гарнизонының Түбән Кама отряды<br>«Татарстан Республикасы Янгын сагы» ДУ<br>«Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр, янгынга каршы куркынычсызлык һәм Түбән Кама муниципаль районының су объектларында кеше иминлеге идарәсе» МКУ<br>«ТР буенча 1 ОФПС (шартнамә)» ФКУ | |
| 25. | Рөхсәт ителмәгән келәтләр урнаштыруны һәм баскыч читлекләрендә һәм коридорларда ягулык материалларын туплауны ачыклау максаты белән, күпфатирлы йортларны атна | даими | Торак-коммуналь оешмалар<br>КЭБ | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | саен йөреп чыгуны оештырырга. Мондый очракларны ачыклаганда, күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенә хәбәр итәргә. | | | |
| 26. | РФдә янгынга каршы режим кагыйдәләренең XX бүлеге нигезендә урман янгыннары куркынычы янаган торак пунктларның паспортларын эшләүне (корректировкалау) оештырырга | 2016 елның марты | Авыл җирлекләре башлыклары<br>КЭБ | |
| 27. | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының янгынга каршы инвентарь туплау пунктларының әзерлеген, муниципаль һәм ирекле янгын сүндерү формированиеләренең хәрби әзерлеген, актлар төзеп, тикшерү оештырырга | 2016 елның апрель-мае | Түбән Кама янгын сүндерү һәм коткару гарнизоны | |
| 28. | Урман фондында янгынга каршы су белән тәэмин итүнең торышын (килү юллары, пирслар, күрсәткечләр) тикшерергә, янгын куркынычы сезоны башланганчыга кадәр ачыкланган җитешсезлекләрне бетерүгә ирешергә | 2016 елның апрель-мае | Түбән Кама янгын сүндерү һәм коткару гарнизоны<br>«Татарстан Республикасы Янгын сагы» ДУ Түбән Кама отряды<br>«ТР буенча 1 ОФПС (шартнамә)» ФКУ | |
| 29. | Хезмәт итүдән азат булган ГПС шәхси составын җыю һәм резерв янгын техникасын исәп-хисапка кертү схемасына һәм тәртибенә төзәтмәләр кертергә | 2016 елның апреле | Түбән Кама янгын сүндерү һәм коткару гарнизоны | |
| 30. | Торак пунктларны (объектларны) саклау һәм тимер юл янындагы янгыннарны сүндерү өчен янгын поездларын җәлеп итү буенча үзара хезмәттәшлек тәртибен ачыкларга | 2016 елның апреле | Түбән Кама янгын сүндерү һәм коткару гарнизоны | |
| 31. | 5 һәм аннан да күбрәк мәйданда табигать янгыны килеп чыкканда яки аның торак пунктларга һәм икътисад объектларына таралу куркынычы янаганда, Түбән Кама муниципаль районының ведомствоара эшче төркеменә хәбәр | факт буенча | «ТР ОФПС 16» ФДУ<br>«Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр, янгынга каршы куркы- | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | итүне һәм җыюны оештырырга. Төркемнең сыйфатлы эше өчен аның эш урынын, табигать янгыннарын бетерү буенча гамәлләр алгоритмын билгеләргә, җәлеп ителгән оешмалар һәм ведомстволар белән хезмәттәшлек мәсьәләләрен, төркем эше өчен формалаштырылган документларны эшләргә. | | нычсызлык һәм Түбән Кама муниципаль районының су объектларында кеше иминлеге идарәсе» МКУ | |
| 32. | 20 һәм аннан да күбрәк мәйданда табигый янгын таралганда, яки түбәндәге очракларда таралганда:<br>1. Торак пункттан 10 км дан кимрәк ераклыкта - резерв янгын техникасын кертергә, ГПС бүлекчәләренең шәхси составын дежур каравылларны көчәйтү өчен ике сменалы эш режимына күчерергә кирәк.<br>2. Торак пункттан 5 км дан кимрәк ераклыкта - ГПС һәм МГПО оператив төркемнәре көчләрен һәм чараларын торак пунктны саклауга чыгаруны тәэмин итәргә. | янгын хәле катлауланган очракта | Түбән Кама янгын сүндерү һәм коткару гарнизоны | |
| 33. | Урман янгыннары белән хәл начарайган очракта, планнан тыш КЧС һәм ПБ үткәрергә | янгын куркынычы чорында | «Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр, янгынга каршы куркынычсызлык һәм Түбән Кама муниципаль районының су объектларында кеше иминлеге идарәсе» МКУ | |
| 34. | «Түбән Кама урман хуҗалыгы» ДБУ һәм «Зәй урманчылыгы» ДБУ белән берлектә урман массивларын һәм урман массивлары янындагы торак пунктларны җир өстендә күзәтү (патрульләү) маршрутларын эшләргә | 2016 елның 1 маена кадәр | «Түбән Кама урманчылыгы» ДБУ<br>«Түбән Кама урман хуҗалыгы» ДБУ<br>Түбән Кама янгын сүндерү һәм коткару гарнизоны<br>КЭБ<br>Эчке эшләр идарәсе | |